**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 23 октябрендәге 722 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 15 апрель
№ 295

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «15» апрелендәге
295 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

### 1. Административ регламентның җайга салу предметы

1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартларын, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны уздыру тәртибенә таләпләр, әлеге Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту рәвешләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының (алга таба шулай ук – Министрлык), аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе билгеләнә.

1.2. Әлеге Административ регламентта файдаланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр:

Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте;

Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Сәламәтлек саклау өлкәсендә

күзәтчелек федераль хезмәтенең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) www.gosuslugi.ru адресы буенча урнашкан «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы – Интернет челтәрендә www.uslugi.tatar.ru адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы;

лицензия – юридик затка яисә шәхси эшкуарга Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып бару хокукы бирә торган махсус рөхсәт, ул Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында алып барыла торган, Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте, Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең территориаль органнары, шулай ук аларга «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 кисәге 1 пункты нигезендә тапшырылган аерым эшчәнлек төрләренә лицензия бирү вәкаләтен башкарганда Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән лицензияләр бердәм реестрында язма нигезендә раслана;

лицензиат – лицензиясе булган юридик зат яисә шәхси эшкуар;

шәхси кабинет – гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылган соратуларны карап тикшерү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә торган Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы сервисы.

1.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән расланган Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында нигезләмәнең (алга таба – Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә) 3 пункты «б» пунктчасы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында түбәндәгеләр лицензияләнергә тиешле:

медицина оешмалары һәм башкалар оешмалар тарафыннан, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм

аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалар, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалардан тыш, алып барыла торган медицина эшчәнлеге;

шәхси эшкуарлар тарафыннан алып барыла торган, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү буенча медицина эшчәнлегеннән тыш, медицина эшчәнлеге;

чит ил юридик затлары – халыкара медицина кластеры проектында катнашучылар тарафыннан алып барыла торган медицина эшчәнлеге.

1.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында лицензия бирелә торган медицина эшчәнлеге составына кергән эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Медицина эшчәнлеген тәшкил итә торган эшләр (хезмәтләр) классификаторын раслау турында» 2021 елның 19 августындагы 866н номерлы карары белән расланды (югары технологияле медицина ярдәме, шулай ук медицина-социаль экспертизасыннан кала).

## 2. Гариза бирүчеләр исемлеге

2.1. Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтүгә сорату (алга таба – сорату) белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән физик затларга, шәхси эшкуарларга, юридик затларга (алга таба – гариза бирүче) яисә аларның вәкаләтле вәкилләренә (алга таба – вәкил) күрсәтелә.

2.2. Гариза бирүчеләр категорияләре:

1) Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып барырга нияте булган һәм Министрлыкка лицензия бирүне сорап мөрәҗәгать иткән (алга таба – лицензия алуга дәгъва кылучылар), Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып бара торган һәм Министрлыкка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүне, лицензияләр гамәлен туктатуны сорап мөрәҗәгать иткән федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмасы булмаган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба – лицензиатлар);

2) Министрлыкка лицензияләр реестрына кертелгән медицина эшчәнлеген башкаруга тәгаен лицензия турында мәгълүмат бирүне сорап мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар;

3) Министрлыкка Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында сорату белән мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар.

2.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең бер варианты (алга таба – вариант) нигезендә күрсәтелә. Вариант әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә гариза бирүченең гомуми сыйфатларыннан, шулай ук әлеге гариза бирүче хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

2.4. Гариза бирүченең сыйфатлары әлеге Административ регламент нигезендә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасын файдаланып, анкета тутыруы (алга таба – профильләштерү) нәтиҗәсендә билгеләнә.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 3. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Дәүләт хезмәтенең атамасы: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)».

### 4. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының атамасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (лицензияләр бирүче орган) тарафыннан тормышка ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры Министрлыкның структур бүлекчәсе – Лицензияләү идарәсе медицина эшчәнлеген башкаруга лицензияләр бирү бүлеге башкара.

4.3. Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре аша, шулай ук экстерриториаль принцип буенча күрсәтелми.

### 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе

5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе:

5.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар:

1) лицензия алган очракта – «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) 21 статьясы 2 кисәге 1–3 һәм 5–8 пунктлары нигезендә билгеләнгән мәгълүматлар кергән лицензияләр реестрында тиешле язма рәвешендә, ә нәкъ менә:

лицензия бирү турында лицензияләр реестрындагы язмага туры килә торган лицензиянең теркәлү номеры, лицензия бирү датасы;

лицензия бирүче органның атамасы (Министрлык);

гариза бирүче – юридик затның тулы һәм кыскартылган (булган

очракта) атамасы, шул исәптән хосусый атамасы һәм оештыру-хокукый формасы, урнашкан урыны адресы, телефон номеры, электрон почта адресы;

лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыны адресы һәм (яисә) лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урынын тәңгәлләштерү мөмкинлеге бирә торган башка мәгълүматлар, юридик зат төзү турында язманың дәүләт теркәвенә алыну номеры;

гариза бирүче – шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документлар атамасы һәм реквизитлары, яшәгән урыны адресы, телефон номеры, электрон почта адресы;

лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыны адресы, һәм (яисә) лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урынын тәңгәлләштерү мөмкинлеге бирә торган башка мәгълүматлар, шәхси эшкуарның дәүләт теркәвенә алынуы турында язманың дәүләт теркәвенә алу номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

лицензияләнә торган эшчәнлек төре булып торган башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтеп, лицензияләнә торган эшчәнлек төре;

лицензия бирүче органның (Министрлыкның) лицензия бирү турында карарының басылып чыгу датасы һәм булган очракта әлеге карарның реквизитлары (шул ук вакытта гариза бирүчегә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен һәм лицензияләр реестрыннан өземтәнең үрнәк формасын раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 2343 номерлы карары белән расланган лицензияләр реестрыннан өземтәнең үрнәк формасы нигезендә рәсмиләштерелгән лицензия бирү турында хәбәрнамә һәм лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында карар җибәрелә;

2) лицензиатның лицензиядә күрсәтелмәгән адрес буенча медицина эшчәнлеге башкару яисә лицензиядә каралган медицина эшчәнлеген тәшкил итүче эшләр, хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү нияте булганда, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгәндә – лицензияләр реестрына кертелгән әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар булган тиешле язма рәвешендә (шул ук вакытта гариза бирүчегә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелү турында хәбәрнамә, шулай ук лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында карар җибәрелә);

3) башка очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгәндә (юридик затны үзгәртеп кору яисә кушылу рәвешендә (кушылуда катнаша торган һәрбер юридик затның яңадан оештырылган юридик затларның хокукый варисын дәүләт теркәвенә алган көнгә медицина эшчәнлеге башкаруга лицензиясе булу шарты белән) яңадан оештырылуы, лицензиатның башка юридик затка кушылуы, лицензиатның атамасы үзгәрүе, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә

лицензияләр реестрына лицензиатның филиалы турында мәгълүматлар буенча үзгәрешләр кертү каралган очракта, лицензиатның филиалының атамасы үзгәрүе, лицензиатның урнашкан урыны адресы үзгәрүе, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә лицензияләр реестрына лицензиатның филиалы урнашкан урыны адресы турында мәгълүматлар буенча үзгәрешләр кертү каралган очракта, лицензиатның филиалы урнашкан урыны адресы үзгәрүе, шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта) үзгәрүе, аның тору урыны үзгәрүе, шәхесен таныклый торган документның реквизитлары үзгәрүе, фактта медицина эшчәнлеге башкару урыны үзгәртелмәгән очракта, юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан медицина эшчәнлеге башкару урыннарының адреслары үзгәртелүе, бер яисә берничә адрес буенча күрсәтелә торган лицензиядә каралган медицина эшчәнлегенең туктатылуы, лицензиядән күрсәтелгән кайбер эшләр (хезмәтләр) башкаруны туктатканда, лицензиатның телефон номеры, электрон почта адресы үзгәрүе, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә лицензия бирелә торган эшчәнлек төренең, медицина эшчәнлеге составында башкарыла торган эшләр, хезмәтләр исемлегенең атамасы үзгәртелүе) – лицензияләр реестрына кертелгән әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар булган тиешле язма рәвешендә (шул ук вакытта гариза бирүчегә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелү турында хәбәрнамә, шулай ук лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында карар җибәрелә);

4) эшчәнлекне туктаткан очракта – лицензияләр реестрына кертелгән 99-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы 2 кисәге 10 пунктында билгеләнгән мәгълүматлар, аерым алганда лицензиянең гамәлен туктатуга нигезләр һәм лицензиянең гамәлен туктату датасы турында мәгълүматлар булган тиешле язма рәвешендә (шул ук вакытта гариза бирүчегә лицензиянең гамәле туктатылу турында хәбәрнамә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында карар җибәрелә);

5) лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар алган очракта – лицензияләр реестрыннан өземтә яисә лицензияләр реестрында соратыла торган мәгълүматларның булмавы турында хәбәрнамә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында карар;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булган очракта – элек бирелгән хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлары булган документка алмашка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган яңа документ рәвешендә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булмавы турында хәбәрнамә.

5.1.2. Хәбәрнамә рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, анда әлеге Административ регламентның 10.2 пунктының тиешле пунктчаларына сылтама белән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр күрсәтелә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүнең сәбәпләре аңлатыла, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш

тарту өчен әлеге нигезләрне хәл иткәннән соң кабаттан Министрлыкка сорату белән мөрәҗәгать итү мөмкинлеге, шулай ук әлеге Административ регламентның V кисәге нигезендә шикаять бирү юлы белән кабул ителгән карарга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирелә.

5.2. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алу факты Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела.

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгән соратулар өчен әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук тиешенчә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында теркәп куела.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелү турында мәгълүматлар, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең электрон образын теркәп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән көнне лицензияләр реестрына кертелә.

5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә лицензияләр реестрыннан өземтә һәм (яисә) тиешле хәбәрнамә рәвешендә электрон формада җибәрелә.

5.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу ысуллары:

1) аңа куелган көнне гариза бирүченең (аның вәкиленең) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталындагы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә;

2) аңа куелган көнне гариза бирүченең (аның вәкиленең) соратуда күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә;

3) әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткәндә соратуда электрон почта адресы күрсәтелмәгән очракта, почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә.

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы:

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 1 пунктчасы нигезендә лицензия алганда – Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча рәсмиләштерелгән сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән 15 эш көненнән дә артык түгел;

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 2 пунктчасы нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгәндә – Министрлык

тарафыннан раслана торган форма буенча рәсмиләштерелгән сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә артык түгел;

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 3 пунктчасы нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгәндә – Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча рәсмиләштерелгән сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән биш эш көненнән дә артык түгел;

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4 пунктчасы нигезендә лицензиянең гамәле туктатылганда – сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән биш эш көненнән дә артык түгел;

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 5 пунктчасы нигезендә лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар алганда – сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә артык түгел;

әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 6 пунктчасы нигезендә хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәткәндә – сорату һәм аңа теркәп бирелә торган документлар (булган очракта) Министрлыкта кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә артык түгел.

6.2. Министрлыкта сорату килгән көннән өч эш көне дәвамында соратуны рәсмиләштерүдә җитешсезлекләр яисә документларның тулы комплекты бирелмәве ачыкланган очракта, Министерство ачыкланган җитешсезлекләрне күрсәтеп, Административ регламентның тиешле пунктларына сылтама белән җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге турында хәбәрнамә юллый. Җитешсезлекләрне бетерү срогы гариза бирүче әлеге хәбәрнамәне алган вакыттан 30 календарь көннән дә артык түгел.

6.3. Җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге турында хәбәрнамә Министрлыкта сорату теркәлгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүченең (аның вәкиленең) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталындагы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына, шулай ук соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына юллана.

6.4. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткәндә, соратуда электрон почта адресы күрсәтелмәгән очракта, җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге турында хәбәрнамә гариза бирүчегә (аның вәкиленә) почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә юллана.

6.5. Гариза бирүче (аның вәкиле) хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы комплектын бирмәгән яисә соратуны рәсмиләштерүдә җитешсезлекләрнең бетерелүен раслый торган төзәтмәләрне кертмәгән очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты гариза бирүчегә соратуны кире кайтаруның сәбәпләрен күрсәтеп, соратуны кире кайтару турында карар кабул итә, карарга

Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела һәм ул гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрнең бетерелүен раслау максатында бирелгән документлар Министрлыкка килгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүченең (аның вәкиленең) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталындагы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына яисә соратуда электрон почта адресы күрсәтелмәгән очракта, әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчегә (аның вәкиленә) почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә юллана.

## 7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, шулай ук Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт), шулай ук Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

## 8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

8.1. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан мөстәкыйль рәвештә бирелергә тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

1) Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча сорату;

2) гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхесен таныклый торган документ;

3) вәкилнең гариза бирүче исеменнән эш йөртүгә вәкаләтләрен раслый торган документ (вәкил мөрәҗәгать иткән очракта).

8.2. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 1 һәм 2 пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче (аның вәкиле) өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

1) гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле булган, аның милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган биналарга, корылмаларга һәм (яисә) алардагы бүлмәләргә Күчемсез милеккә һәм алар белән эш итүгә хокуклар бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән хокукын раслый торган документларның

күчермәләре (әлеге хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән очракта – гариза бирүченең әлеге биналар, корылмалар һәм алардагы бүлмәләргә хокукы булуын раслый торган документларның реквизитлары турында мәгълүмат);

2) гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле булган, аның милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган медицина эшләнмәләренә (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментларга) хокукын раслый торган документларның күчермәләре яисә гариза бирүче тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм  медицина һәм фармация хезмәткәрләре бердәм системасы федераль регистрына тиешле мәгълүматлар кертелгән очракта, сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм  медицина һәм фармация хезмәткәрләре федераль регистрына тиешле мәгълүматлар кертелү турында мәгълүматлар;

3) гариза бирүче белән хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләрнең медицина һәм фармация хезмәткәрләренә куелган квалификация таләпләре нигезендә каралган белеме һәм белгечнең аккредитация узуы яисә гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле белгеч сертификаты булуын раслый торган документларның реквизитлары яисә күчермәләре – әлеге документлар турында мәгълүматлар «Белем һәм (яисә) квалификация турында документлар, уку турында документлар хакында мәгълүматларның федераль реестры» федераль мәгълүмат системасында һәм Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды мәгълүмат системасында булмаган очракта яисә гариза бирүче тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм медицина һәм фармация хезмәткәрләре бердәм системасы федераль регистрында булмаган очракта, сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм  медицина һәм фармация хезмәткәрләре бердәм системасы федераль регистрына тиешле мәгълүматлар кертелү турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче белән хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләрнең медицина эшләнмәләренә (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментларга) техник хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең тиешле һөнәри белеме һәм (яки) квалификациясе булуын раслый торган документларның реквизитлары яисә күчермәләре – әлеге документлар турында мәгълүматлар «Белем һәм (яисә) квалификация турында документлар, уку турында документлар хакында мәгълүматларның федераль реестры» федераль мәгълүмат системасында һәм Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды мәгълүмат системасында булмаган очракта яисә тиешле эшчәнлек алып барырга лицензиясе булган оешма белән шартнамә күчермәсе.

8.3. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гариза бирүче (аның вәкиле) мөстәкыйль рәвештә бирергә хокуклы булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиешле документларның тулы исемлеге:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (дәүләт хезмәте алучы юридик зат булган очракта);

2) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (дәүләт хезмәте алучы шәхси эшкуар булган очракта).

8.3.1. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 1 һәм 2 пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче (аның вәкиле) үз теләге белән өстәмә рәвештә түбәндәгеләр бирелә:

1) гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле булган, аның милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган биналарга, корылмаларга һәм (яисә) алардагы бүлмәләргә Күчемсез милеккә һәм алар белән эш итүгә хокуклар бердәм дәүләт реестрында теркәлгән хокукын раслый торган документларның күчермәләре;

2) гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм (яисә) Евразия икътисадый берлеге хокукы бирә торган халыкара шартнамәләр һәм актлар нигезендә теркәлгән медицина эшләнмәләрен (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментларга) дәүләт теркәве турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм медицина һәм фармация хезмәткәрләре бердәм системасы федераль регистрына тиешле мәгълүматлар кертелгән очракта, сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасында медицина һәм фармация оешмалары федераль реестрына һәм медицина һәм фармация хезмәткәрләре бердәм системасы федераль регистрына тиешле мәгълүматлар кертелү турында мәгълүматлар;

3) гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле биналарның, корылмаларның һәм (яисә) бүлмәләрнең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булу турында мәгълүматлар;

4) дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүматлар (документ) (дәүләт пошлинасы түләү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән булса).

8.3.2. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 3 пунктчасы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче (аның вәкиле) үз теләге белән өстәмә рәвештә дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүматлар (документ) (дәүләт пошлинасы түләү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән булса) бирә.

8.4. Гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан сорату түбәндәге ысуллар белән бирелә ала:

1) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша;

3) почта аша заказлы хат рәвешендә кәгазь чыганакта – бары тик әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4,6 пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә.

8.5. Министрлык дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мәгълүмат алу өчен түбәндәге оешмаларга ведомствоара соратулар юллый:

1) Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

а) гариза бирүче турында язманың юридик затлар өчен – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуарлар өчен – Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелүе фактын раслый торган мәгълүмат бирү турында;

б) гариза бирүче – юридик затның, шәхси эшкуарның Россия Федерациясе территориясендә урнашу җире буенча салым органында исәпкә басу фактын раслый торган мәгълүматлар бирү турында;

2) Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – гариза бирүчегә милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган биналар, корылмалар һәм (яисә) алардагы бүлмәләргә Күчемсез милеккә һәм алар белән эш итүгә хокуклар бердәм дәүләт реестрында теркәлгән хокукы булуы фактын раслый торган мәгълүмат бирү турында;

3) Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә – гариза бирүченең лицензия алуга дәгъва кылучыга яисә лицензиатка гаризада күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле биналарның, корылмаларның һәм (яисә) бүлмәләрнең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе алуы фактын раслый торган мәгълүматлар бирү турында;

4) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләве фактын раслый торган мәгълүматлар бирү турында.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматларны үз телән белән бирергә хокуклы.

## 9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) башка дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

2) элегрәк теркәлгән, әлеге сорату килгән вакытка аның буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты тәмамланмаган соратуга тәңгәл соратуның килүе;

3) гариза бирүченең категориясе әлеге Административ регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән затлар исемлегенә кермәве;

4) лицензия бирелергә тиешле медицина эшчәнлеген башкару урынының Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан булуы;

5) югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү, шулай ук медицина-социаль экспертиза уздыру өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

6) аңа мөнәсәбәтле рәвештә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелергә тиешле, шул исәптән эшчәнлеген туктату өлешендә, медицина эшчәнлеген башкару урынының Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан булуы.

9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, документлар почта аша заказлы хат рәвешендә кәгазь чыганакта бирелгән очрактан тыш (әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары), Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында рәсмиләштерелә һәм урнаштырыла, гариза бирүченең Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында күрсәтелә.

9.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү гариза бирүченең (аның вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кабаттан Министрлыкка мөрәҗәгать итүенә киртә була алмый.

## 10. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан бирелгән соратуда һәм (яисә) аңа теркәп бирелгән документларда (мәгълүматларда) 99-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә ачыкланган дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүматларның булуы;

2) гариза бирүче әлеге Административ регламентның 5.11 пункты 1 һәм 2 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең 99-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү барышында аның Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

3) әлеге Административ регламентның 5.11 пункты 1 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать килгән очракта, Министрлыкка медицина эшчәнлеген башкаруга лицензия бирүне сорап мөрәҗәгать иткән гариза бирүченең әлеге төр эшчәнлекне башкаруга гамәлдәге лицензиясе булуы;

4) әлеге Административ регламентның 5.11 пункты 5 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать килгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яисә хезмәт серен саклау хакына лицензияләр реестрындагы мәгълүматлардан ирекле рәвештә файдалану мөмкинлегенең чикләнгән булуы.

10.3. Соратуны кире кайтару өчен нигезләр булып гариза бирүченең (аның вәкиленең) әлеге Административ регламентның 6.2–6.4 пунктларында күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү турында хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы комплектын бирмәве яисә сорату формасында кимчелекләрне бетерүне раслый торган төзәтмәләрнең кертелмәве.

10.4. Соратуны кире кайтару өчен әлеге Административ регламентның 10.3 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты гариза бирүчегә соратуны кире кайтаруның сәбәпләрен күрсәтеп, соратуны кире кайтару турында карар кабул итә, карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела һәм хәбәрнамәдә күрсәтелгән кимчелекләрнең бетерелүен раслау максатында гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан бирелгән документлар Министрлыкка килгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүченең Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына яисә соратуда электрон почта адресы күрсәтелмәгән очракта, әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне алу өчен почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә юллана.

10.5. Гариза бирүче ирекле формада язылган гариза нигезендә, аны Министрлыкның электрон почта адресына юллап, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында килгән гариза нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуы турында факт Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту гариза бирүченең (аның вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кабаттан Министрлыкка мөрәҗәгать итүенә киртә була алмый.

10.6. Гариза бирүче әлеге Административ регламентның 10.2 һәм 10.3 пунктларында күрсәтелгән кимчелекләрне бетергәннән соң кабаттан Министрлыкка сорату белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## 11. Гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган түләүнең күләме һәм аны алу ысуллары

11.1. Дәүләт пошлинасы турында мәгълүматлар Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен (лицензия бирү һәм лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү) дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының $333^{33}$ статьясы 1 пункты 92 пунктчасы нигезендә билгеләнгән күләмдә түләнә.

«Россия Федерациясендә рөхсәт кәгазьләре бирү эшчәнлегенең үзенчәлекләре турында» 2022 елның 12 мартындагы 353 номерлы карарының 9 пункты нигезендә 2029 елның 31 декабренә кадәр лицензия бирү яисә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләү таләп ителми.

11.2. Гариза бирүче әлеге Административ регламентның 4–6 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

11.3. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында түләү сервислары ярдәмендә түләү мөмкинлеге бирелә.

11.4. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат Министрлык тарафыннан Дәүләт һәм муниципаль түләүләр дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны файдаланып алына.

11.5. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтелүдән баш тарткан очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла.

Лицензияләр реестрыннан күчермә рәвешендә һәм Министрлыкның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бушлай бирелә.

11.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының гаебе нәтиҗәсендә җибәрелгән хаталарны төзәтергә дип кире кайтарылган документка үзгәрешләр кертелгән очракта, гариза бирүчедән акча алынмый.

### 12. Гариза бирүче (аның вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Гариза бирүче (аның вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы билгеләнми, чөнки дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны юллау һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә, шулай ук әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә почта аша заказлы хат рәвешендә кәгазь чыганакта башкарыла.

### 13. Гариза бирүченең (аның вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуын теркәү срогы

Министрлыкта соратуны теркәү срогы:

1) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә эш көненең 16:00 сәгатенә кадәр килгәндә – сорату килгән көнне, эш көнендә 16:00 сәгатьтән соң яисә ял көнендә килгәндә – икенче эш көнендә;

2) почта аша килгәндә (әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә килгән соратулар) – сорату килгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча.

### 14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр куелмый, чөнки гариза Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә, шулай ук әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 4, 6 пунктчалары нигезендә почта аша заказлы хат рәвешендә кәгазь чыганакта бирелә.

### 15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты күрсәткечләре

15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләр:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларның электрон

рәвешләренең ачык кулланышта булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтенең үз вакытында күрсәтелүе (дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын үтәмәү очракларының булмавы);

дәүләт хезмәтенең дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә күрсәтелүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган түләүләрне (кирәк булган очракта) башкару өчен инструментларның ачык кулланышта булуы;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу турында хәбәр итүдә уңайлылыклар;

гариза бирүчеләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.

15.2. Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты күрсәткечләре исемлеге турында мәгълүмат урнаштырыла.

## 16. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы башка таләпләр

16.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге:

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы;

Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы;

электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләү бердәм системасы;

сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасы;

Бердәм кучемсез милек дәүләт реестрын алып бару федераль дәүләт системасы;

Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы;

«Белем һәм (яисә) квалификация турында документлар, уку турында документлар хакында мәгълүматларның федераль реестры» федераль мәгълүмат системасы (мәгълүматлар булган очракта);

ведомствоара электрон хезмәттәшлек бердәм системасы;

федераль мәгълүмати адреслы хезмәт.

16.2. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре:

сорату Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә бирелгән очракта, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы дәүләт хезмәте карточкасында аның интерактив формасы тутырыла, аңа документларның электрон образлары теркәп бирелә һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлардагы белешмәләр күрсәтелә;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризага, шулай ук гариза бирүче Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гамәлләр башкару турында электрон документлар рәвешендә бирергә тиешле гаризаларга көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куела;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең әзерлеге турында хәбәр итү Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына хәбәрнамә җибәрү аша бушлай нигездә башкарыла.

## III. Административ процедураларның составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары

17. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге

17.1. Федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмалары булмаган, Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып барырга нияте булган яисә медицина эшчәнлеге алып бара торган юридик затлар яки әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 1,2 пунктчалары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып барырга нияте булган яисә медицина эшчәнлеге алып бара торган шәхси эшкуарлар мөрәҗәгать иткәндә.

17.2. Федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмалары булмаган, Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып бара торган юридик затлар яки әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 3,4 пунктчалары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып бара торган шәхси эшкуарлар мөрәҗәгать иткәндә.

17.3. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 5 пунктчасы нигезендә физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар мөрәҗәгать иткәндә.

17.4. Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пункты 6 пунктчасы нигезендә физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар мөрәҗәгать иткәндә.

## 18. Гариза бирүчене профильләштерү административ процедурасы тасвирламасы

18.1. Гариза бирүчегә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантын ачыклау һәм дәүләт хезмәте күрсәтү:

1) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша;

2) Министрлыкның рәсми сайты аша;

3) Министрлыкта.

18.2. Гариза бирүчегә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантын ачыклау һәм дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе:

1) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында сорауларга җавап бирү аша;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында сорауларга җавап бирү аша;

3) Министрлыкта сораштыру уздыру аша.

18.3. Әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә гариза бирүчеләр категорияләре алар нигезендә берләштерелә торган гомуми сыйфатлар исемлеге, шулай ук гариза бирүченең һәркайсы дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларының берсенә туры килә торган сыйфатлары комбинацияләре исемлеге бирелә.

## 19. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары тасвирламасы

19.1. Әлеге Административ регламентның 17.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр (процедуралар) башкарыла:

соратуны, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән соратуны һәм документларны карап тикшерү мөмкинлеге турында карар кабул итү;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

гариза бирүченең 99-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү;

дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

19.2. Әлеге Административ регламентның 17.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр (процедуралар) башкарыла:

соратуны, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән соратуны һәм документларны карап тикшерү мөмкинлеге турында карар кабул итү;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

19.3. Әлеге Административ регламентның 17.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр (процедуралар) башкарыла:

соратуны, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

19.4. Әлеге Административ регламентның 17.4 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр (процедуралар) башкарыла:

соратуны, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

19.5. Әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә lәүләт хезмәтен күрсәтү вариантына бәйле рәвештә административ гамәлләр (процедуралар) тасвирламасы бирелә.

## IV. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

### 20. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлеше, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту тәртибе

20.1. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлеше, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры һәм ул вәкаләтләр биргән вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла.

20.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контроль уздыру тәртибе һәм формаларына таләпләр:

1) бәйсезлек;

2) җентеклелек.

20.2.1. Агымдагы контрольнең бәйсез уздырылуы дигәндә Министрлыкның агымдагы контроль уздыруга вәкаләтле вазыйфаи заты Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи заты белән хезмәт вазыйфаларын башкарганда бер-берсенә бәйле булмавы, шул исәптән бер-берсенә якын туган яисә үги туган (әтисе-әнисе, ире (хатыны), балалары, абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, шулай ук иренең (хатынының) абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, әтисе-әнисе, балалары һәм балаларының ирләре (хатыннары) булып тормавы күздә тотыла.

Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне алып баручы вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәткәндә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау чараларын күрергә тиеш.

20.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне җентекле уздыру Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затларының әлеге бүлектә күрсәтелгән вазыйфаларны башкаруыннан гыйбарәт.

20.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән алып барыла.

Агымдагы контроль даими нигездә алып барыла.

20.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүдән, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, гариза бирүчеләрнең Министрлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләре белдерелгән мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүдән, алар буенча карарлар кабул итүдән һәм җаваплар әзерләүдән тора.

## 21. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм дәвамлылыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатын контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары

21.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм дәвамлылыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатын контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары Министрлыкның оештыру-күрсәтмә документлары нигезендә билгеләнә.

Планлы тикшерүләр яртыеллык һәм еллык эш планнары нигезендә уздырыла.

Планнан тыш тикшерүләр вакытында дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яисә аерым мәсьәләләр (тематика тикшерүләр), шулай ук әлеге Административ регламентны үтәмәү белән бәйле элегрәк ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне тикшерү яки Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр алу белән бәйле мәсьәләләрне кертеп, карап тикшерелә.

21.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру барышында Россия Федерациясе законнары, әлеге Административ регламентның нигезләмәләрен дә кертеп, үтәлешендә җитешсезлекләр ачыкланган очракта, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге җитешсезлекләрне бетерү чаралары күрелә.

## 22. Вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән һәм гамәлгә ашырылган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплылыгы

22.1. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары алар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау), шул исәптән әлеге Административ регламент нигезендә билгеләнгән административ процедураларны башкару срокларын үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

22.2. Министрлыкның лицензия эшен карап тикшерү һәм алып бару йөкләнгән вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты, шулай ук гариза бирүчегә тиешле мәгълүматның җиткерелүе өчен шәхси җаваплы була.

22.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен шәхси җаваплылык Министрлыкның вазыйфаи затларының вазыйфаи регламентларында раслана.

22.4. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен үтәү өчен җаваплы вазыйфаи заты булып Министрлыкның турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтә торган структур бүлекчәсе җитәкчесе тора.

## 23. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольне алып бару тәртибе һәм формалары

23.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контроль әлеге Административ регламентның 20.1–22.4 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә һәм формаларда алып барыла.

23.2. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольне алып бару өчен Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен камилләштерү буенча тәкъдимнәр белән шәхси һәм коллектив мөрәҗәгатьләр юлларга, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм алар тарафыннан кабул ителгән карарларга шикаять белдерергә һәм гариза язарга хокуклы.

23.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар дәүләт хезмәте күрсәтүгә контроль әлеге Административ регламентта каралган тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүматны алу, шулай ук Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул иткән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм шикаять белдерү юлы белән алып барыла.

## V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

### 24. Гариза бирүчеләргә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында хәбәр итү ысуллары

Гариза бирүчеләргә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннардагы стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мәгълүмат урнаштыру, шулай ук гариза бирүчеләргә, шул исәптән телефон аша, электрон почтага яисә шәхсән кабул итү барышында консультацияләр бирү аша хәбәр ителә.

### 25. Гариза бирүчеләр тарафыннан шикаять бирү формалары һәм ысуллары

25.1. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның $11^4$ статьясында билгеләнгән таләпләрне үтәп башкарыла.

25.2. Шикаять бирү вакыты гамәлен дәвам иттерүгә шикаять һәм үтенечнамә гариза бирүче үзенең хокуклары бозылу турында белгән яисә белергә тиеш булган вакыттан 30 календарь көн эчендә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Интернет челтәре ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтү барышында Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша электрон рәвештә бирелә.

---

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

**Гариза бирүчеләр категорияләре алар нигезендә берләштерелә торган гомуми сыйфатлар исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең һәркайсы дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларының берсенә туры килә торган сыйфатлары комбинацияләре**

**Гариза бирүчеләрнең категорияләре алар нигезендә берләштерелә торган гомуми сыйфатлар**

| Т/с | Гомуми сыйфатлар | Гариза бирүчеләр категорияләре |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып барырга нияте булган һәм Министрлыкка лицензия бирүне сорап мөрәҗәгать иткән, Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеге алып бара торган һәм Министрлыкка | Гариза бирүчеләрнең әлеге Административ регламентның 2.2 пунктының 1 пунктчасы нигезендә категориясе |

| Т/с | Гомуми сыйфатлар | Гариза бирүчеләр категорияләре |
|---|---|---|
| | лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүне, лицензияләр гамәлен туктатуны сорап мөрәҗәгать иткән федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмасы булмаган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар | |
| 2 | Министрлыкка лицензияләр реестрына кертелгән медицина эшчәнлеген башкаруга тәгаен лицензия турында мәгълүмат бирүне сорап мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар | Гариза бирүчеләрнең әлеге Административ регламентның 2.2 пунктының 2 пунктчасы нигезендә категориясе |
| 3 | Министрлыкка Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында сорату белән мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар | Гариза бирүчеләрнең әлеге Административ регламентның 2.2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә категориясе |

## Гариза бирүчеләрнең һәркайсы дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларының берсенә туры килә торган сыйфатлары комбинацияләре

| Т/с | Сыйфатлар комбинацияләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү варианты |
|---|---|---|
| 1 | Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 1, 2 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткән юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар | Әлеге регламентның 17.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты |
| 2 | Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 3, 4 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткән юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар | Әлеге регламентның 17.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты |
| 3 | Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 5 пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар | Әлеге регламентның 17.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты |
| 4 | Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 6 пунктчалары нигезндә мөрәҗәгать иткән физик затлар, шәхси | Әлеге регламентның 17.4 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты |

| Т/с | Сыйфатлар комбинацияләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү варианты |
|---|---|---|
| | эшкуарлар, юридик затлар | |

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү вариантына бәйле рәвештә административ гамәлләр (процедуралар) тасвирламасы**

**1 вариант. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының федераль законнар нигезендә хәрби һәм аңа тиңдәш булган хезмәт үтү күздә тотылган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш)» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 17.1 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү**

1.1. Соратуны, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлләрне (процедураларны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы / Министрлык / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырыл-ган мәгълүмат системасы | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле соратуларны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү һәм аларга, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булу-булмауга башлангыч тикшерү уздыру, соратуны теркәү яисә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү | Бер эш көне | Гариза бирүче (аның вәкиле) биргән соратуның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яисә) мәгълүматның Россия Федерациясе законнары, шул исәптән әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүе | Гариза бирүчедән (аның вәкиленнән) сорату алыну административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора.<br>Сорату Министрлык раслаган форма нигезендә рәсмиләштерелә.<br>Соратуны вәкил биргәндә, аңа әлеге Административ регламентның 8.1 пунктының 2,3 пунктчаларында күрсәтелгән документлар теркәп бирелә.<br>Соратуга әлеге Административ регламентның 8.2 пунктында күрсәтелгән документлар теркәп бирелә.<br>Гариза бирүче (аның вәкиле) үз теләге белән әлеге Административ регламентның 8.3 һәм 8.3.1 пунктларында күрсәтелгән документларны бирергә мөмкин.<br>Гариза бирүче (аның вәкиле) соратуны Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирергә мөмкин.<br>Гариза бирүче (аның вәкиле) соратуны биргәндә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | порталында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләү бердәм системасында расланган исәп язмасы аша гамәл кылуга хокукын раслый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләү бердәм системасында расланган исәп язмасы аша гамәл кылуга хокук расланганда сорату гариза бирүченең (аның соратуга кул куярга вәкаләте булган вәкиленең) гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.<br>Министрлыкның вазыйфаи заты соратуга әлеге Административ регламентның 9.1 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булу-булмауга кагылышлы тикшерү уздыра.<br>Мондый нигезләр булган очракта, Министрлык Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар формалаштыра. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела һәм сорату алынган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинетына юллана.<br>Әгәр мондый нигезләр булмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында соратуны терки.<br>Соратуны Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәү яисә гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар юллау административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |

## 1.2. Соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кабул ителгән документларны карап тикшерү мөмкинлеге турында карар кабул итү

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлне (процедураны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Министрлык / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы | Соратуда Россия Федерациясе законнарында каралган мәгълүматның тулы күләмдә булу-булмавын, шулай ук кирәкле барлык документларның булу-булмавын тикшерү | Ике эш көне | Соратуда Россия Федерациясе закон-нарында каралган мәгълүматның тулы күләмдә булу-булмавын, шулай ук документларның тулы комплекты булу-булмавын тикшерү | Соратуны теркәү административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора.<br>Сорату һәм бирелгән документлар 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, шулай ук әлеге Административ регламентның 8.1 һәм 8.2 пунктлары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе тикшерелә.<br>Соратуда 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган мәгълүмат тулы күләмендә булмаган һәм (яисә) әлеге Административ регламентның 8.1 һәм 8.2 пунктларында каралган кирәкле документлар тулы күләмендә булмаган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты җитешсезлекләрне 30 көн эчендә бетерергә кирәклеге турында хәбәрнамә рәсмиләштерә.<br>Әлеге хәбәрнамәгә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела һәм сорату алынган көннән соң өч эш көне |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дәвамында Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинетына юллана.<br>Хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерүне раслый торган документлар гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинеты аша электрон рәвештә хәбәрнамә алынган көннән 30 календарь көн эчендә бирелә.<br>Гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрнең бетерелүен раслаучы документлар бирелгән көннән өч эш көне дәвамында Министрлыкның вазыйфаи заты бирелгән документларның 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында һәм (яисә) әлеге Административ регламентның 8.1 һәм 8.1.1 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.<br>Әгәр бирелгән документларда хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрнең бетерелүе расланса, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты соратуны һәм аңа теркәп биргән документларны карап тикшерү мөмкинлеге турында карар кабул итә һәм бу |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | мәгълүматны Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштыра. Соратуны һәм аңа теркәп бирелгән документларны карап тикшерү мөмкинлеге турында карар кабул ителү административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора. Административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |
| | Ачыкланган җитешсезлекләрнең гариза бирүче тарафыннан бетерелмәве сәбәпле соратуны кире кайтару | Гариза бирүче тарафыннан җитешсезлек-ләрне бетеррергә кирәклеге ту-рында хәбәрнамә алынган вакыт-тан 30 календарь көн | Соратуда Россия Федерациясе законнарында каралган мәгълүматның тулы күләмдә булмавы, шулай ук документларның тулы комплекты булмавы | Гариза бирүченең (аның вәкиленең) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тулы күләмдә бирмәве, шулай ук соратуны рәсмиләштергәндә җитешсезлекләрнең төзәтелүен раслый торган төзәтмәләрнең булмавы административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора. Әгәр җитешсезлекләрне бетерү өчен бирелгән документлар хәбәрнамәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрнең бетерелүен расламаса, Министрлыкның вазыйфаи заты соратуны һәм аңа теркәлгән документларны кайтарып бирү турында карар рәсмиләштерә. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әлеге карарга Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела һәм Министрлыкта гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан хәбәрнамәдә күрсәтелгән житешсезлекләрнең бетерелүен раслау өчен бирелгән документлар алынган көннән соң өч эш көненнән соңга калмыйча Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинетына юллана.<br>Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинетына соратуны һәм аңа теркәп бирелгән документларны кире кайтару турындагы карарның юллануы административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |

## 1.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлне (процедураны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Министрлык / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы / сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасы | Органнар һәм оешмалардан соратылырга тиешле документлар һәм (яисә) мәгълүматлар составын билгеләү, ведомствоара мәгълүмати сорату юллау | Бер эш көне | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә органнар һәм оешмалар карамагындагы документларның булу-булмавы | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә органнар һәм оешмалар карамагындагы документларның һәм (яисә) мәгълүматларның булу-булмавы административ гамәлне (процедураны) башлау, шулай ук ведомствоара мәгълүмати сорату юллау өчен нигез булып тора.<br>Министрлыкның вазыйфаи заты ведомствоара соратуларын тутыра һәм түбәндәге федераль башкарма хакимият органнарына юллый:<br>1. Федераль салым хезмәте, бу вакытта гариза бирүчегә – юридик затка карата салым түләүченең идентификация номеры күрсәтелә һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратыла, анда гариза бирүченең юридик зат яисә шәхси эшкуар буларак Россия Федерациясе территориясендә теркәлүен раслау өчен, шулай ук гариза бирүче соратуда күрсәткән мәгълүматларның дөреслеген тикшерү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматлар бирелә:<br>1) гариза бирүченең тулы атамасы;<br>2) гариза бирүченең кыскартылган атамасы (булган очракта); |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | 3) гариза бирүченең төп дәүләт теркәү номеры;<br>4) салым түләүченең идентификация номеры;<br>5) гариза бирүченең урнашкан урыны адресы;<br>6) гариза бирүче җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);<br>7) гариза бирүче җитәкчесенең вазыйфасы;<br>шул ук вакытта әлеге соратуда гариза бирүче – шәхси эшкуарга карата салым түләүченең идентификация номеры күрсәтелә һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратыла, анда түбәндәге мәгълүматлар бирелә:<br>1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);<br>2) гариза бирүченең кыскартылган атамасы (булган очракта);<br>3) гариза бирүченең төп дәүләт теркәү номеры;<br>4) гариза бирүченең-салым түләүченең идентификация номеры;<br>2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте, бу вакытта әлеге соратуда гариза бирүченең хокукы булган объектның кадастр номеры күрсәтелә һәм Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә соратыла, анда милек хокукы яисә башка төрле законлы нигездә гариза бирүченең аларга хокукы теркәлгән, аталган эшчәнлек |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | төрләрен башкару өчен кирәкле биналары булуны раслау өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматлар бирелә:<br>1) күчемсез милек объектының кадастр номеры;<br>2) күчемсез милек объектының адресы;<br>3) күчемсез милек объектының мәйданы;<br>4) күчемсез милек объектының билгеләнеше;<br>5) күчемсез милек объектына хокукка ия булучылар турында белешмә;<br>3. Сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәте, шул ук вакытта әлеге соратуда анда гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән медицина эшләнмәләренең теркәү таныклыклары номерлары күрсәтелә һәм гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән эшләр (хезмәтләр) башкару өчен кирәкле медицина эшләнмәләренең (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментлар) дәүләт теркәве узуы турында медицина эшләнмәләренең теркәү узуы турындагы соратуда китерелгән мәгълүматларны тикшерү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматлар китерелә:<br>1) медицина эшләнмәсенең теркәү номеры;<br>2) медицина эшләнмәсенең теркәү узуы датасы;<br>3) медицина эшләнмәсенең теркәү таныклыгының гамәле вакыты;<br>4) медицина эшләнмәсенең атамасы;<br>4. Кулланучылар хокукларын һәм кеше |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте, шул ук вакытта әлеге соратуда санитария-эпидемиология бәяләмәсе номеры күрсәтелә һәм биналарның санитария таләпләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булуы-булмавы турында гариза бирүченең лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкарганда дәүләт санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү-килмәвен тикшерү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматлар соратыла:<br>1) бәяләмә номеры;<br>2) бәяләмә бирелгән вакыт;<br>3) гариза бирүченең тулы атамасы;<br>4) гариза бирүченең төп дәүләт теркәве номеры;<br>5) салым түләүченең идентификация номеры;<br>6) гариза бирүченең урнашкан урыны адресы;<br>7) гариза бирүченең медицина эшчәнлеген башкару объекты адресы;<br>8) гариза бирүчегә башкару (хезмәт күрсәтү) өчен рөхсәт ителгән медицина эшчәнлеген тәшкил итә торган эшләр (хезмәтләр) исемлеге;<br>5. Федераль казначылык, шул ук вакытта әлеге соратуда гариза бирүченең салым түләүче буларак идентификация номеры яисә гариза бирүченең шәхесен таныклый |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | торган документ номеры күрсәтелә һәм гариза бирүченең дәүләт пошлинасын түләве турында дәүләт һәм муниципаль түләүләр дәүләт мәгълүмат системасыннан гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләнүе фактын раслау өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматлар соратып алына:<br>1) квитанция яисә түләү йөкләмәсе номеры;<br>2) түләү датасы;<br>3) түләүченең тулы атамасы яисә фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);<br>4) түләүченең салым түләүче буларак идентификация номеры яисә түләүченең шәхесен таныклый торган документ номеры;<br>5) түләү суммасы;<br>6) түләүнең билгеләнеше.<br>Ведомствоара мәгълүмат соратулары Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында рәсмиләштерелә. Министрлыкның гариза бирүчене бәяләүне уздыра торган вазыйфаи заты гариза бирүченең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ашырылган очраклардан тыш) турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән билгеләнгән лицензияләү таләпләренә туры килүен раслау өчен сәламәтлек саклау өлкәсе бердәм дәүләт мәгълүмат системасында гариза бирүче турында (медицина һәм фармацевтика оешмалары федераль реестрында) гариза бирүче һәм гариза бирүче белән соратуда күрсәтелгән лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил иткән эшләр (хезмәтләр) башкаруга хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләр турында (медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре федераль регистрында) мәгълүматлар урнаштырылуын тикшерә, атап әйткәндә:<br>1). Медицина һәм фармацевтика оешмалары федераль реестрында:<br>а) түбәндәгеләр булып торучы гариза бирүче турында гомуми мәгълүматлар:<br>юридик зат (тулы атамасы, кыскартылган атамасы (булган очракта, сәламәтлек саклау өлкәсе субъекты, оештыру дәрәҗәсе, оештыру төре, ведомство карамагында булуы, эшчәнлек төре, салым түләүче буларак идентификация номеры, исәпкә кую сәбәпләре коды, төп дәүләт теркәве номеры, юридик затның адресы);<br>шәхси эшкуар (фамилиясе, исеме, атасының |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | исеме (булган очракта), салым түләүче буларак идентификация номеры, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, яшәгән урыны адресы).<br>б) лицензияләнә торган эшчәнлек төре башкару планлаштырыла торган яисә башкарыла торган биналар турында мәгълүматлар;<br>в) гариза бирүченең структур бүлекчәләре турында мәгълүматлар;<br>г) гариза бирүченең җиһазлары турында мәгълүматлар.<br>2. Сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт мәгълүмат системасының медицина һәм фармацевтика бердәм системасы хезмәткәрләре федераль регистрында, гариза бирүче белән соратуда күрсәтелгән лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил иткән эшләр (хезмәтләр) башкаруга хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләр (алга таба шулай ук – гариза бирүченең хезмәткәрләре):<br>а) гариза бирүченең хезмәткәрләре турында төп мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), җенесе, туган вакыты, туган урыны, гражданлыгы, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре, яшәү урыны, теркәлү урыны, теркәлү датасы, шәхси хисап счеты иминиятләштерү номеры (булган очракта);<br>б) гариза бирүченең хезмәткәре белеме турында мәгълүмат (медицина белеме бирү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | һөнәри мәгариф программаларын гамәлгә ашыру буенча мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешмалар, белгечнең белеме һәм (яисә) квалификациясе, эш урынын алдан билгеләп белем алу турында төзегән шартнамә турында белешмәләр, белгечнең сертификаты яисә белгечнең аккредитациясе турында белешмәләр);<br>в) гариза бирүче хезмәткәренең эшкә урнашуы турында мәгълүматлар (медицина оешмасы, медицина оешмасының структур бүлекчәсе, вазыйфасы, вазыйфасы буенча башкара торган эш төре, ставкасы, эшли башлаган көне, эштән туктаган көне, эштән туктауга нигезләр).<br>Ведомствоара мәгълүмати соратулар юллау административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Нәтиҗә электрон рәвештә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |
| | Ведомствоара мәгълүмати сорату нәтиҗәсен бирүгә контроль | Биш эш көненнән артып китәргә тиеш түгел | | Ведомствоара мәгълүмати соратуларга җавап килүне тикшерү.<br>Ведомствоара мәгълүмати соратуларга җавап алу административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Нәтиҗә электрон рәвештә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |

## 1.4. Гариза бирүченең 99-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләүне уздыру

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлне (процедураны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Министрлык / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы | Гариза бирүчеләрнең медицина эшчәнлеген башкарганда лицензияләү таләпләрен үтәүләрен бәяләү | Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта, 12 эш көне.<br>Әлеге Административ регламентның 5.1.1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта, 7 эш көне. | Гариза бирүченең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер | Министрлыкның соратуны карап тикшерү турындагы карары административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора.<br>Гариза бирүчеләр тарафыннан медицина эшчәнлеген башкарганда лицензия таләпләрен үтәвен бәяләүне (лицензия контролен) уздыру өчен Министрлыкның вазыйфаи заты Министрлыкның гариза бирүчене бәяләүне уздыру турында боерыгы проектын әзерли, ул Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана.<br>Гариза бирүчене экспертизалап бәяләү предметы булып бирелгән соратудагы һәм документлардагы мәгълүматларны аларның 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта ) яисә 18 статьясында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүе | мөрәҗәгать иткән очракта), «Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән расланган Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында нигезләмәнең 5,8 пунктларында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта) яисә 5,11 пунктларында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта) билгеләнгән нигезләмәләргә, шулай ук ведомствоара мәгълүмати соратуларга җаваплардагы гариза бирүче турында мәгълүматларга туры килүен раслау максатларында тикшерү тора.<br>Югарыда күрсәтелгән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары бозылу ачыкланган очракта, шулай ук ведомствоара |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | мәгълүмати соратуларга җаваплардагы гариза бирүче турында мәгълүматларга туры килмәгән очракта гариза бирүчене урынга барып бәяләү уздырылмый.<br>«Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән расланган Медицина эшчәнлеген лицензияләү (әлеге эшчәнлек «Сколково» инновация үзәге территориясендәге медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына кертелгән башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) турында нигезләмәнең 5 пункты белән билгеләнгән лицензия таләпләренең гариза бирүче тарафыннан үтәлү мөмкинлеген тикшерү турыдан-туры гариза бирүчене лицензияләнергә тиешле медицина эшчәнлеген башкару урынына чыгып бәяләүнең предметы булып тора.<br>Гариза бирүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләү турында Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты кул куйган актны рәсмиләштерү административ гамәлнең (процедураның) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | нәтиҗәсе булып тора. Лицензия таләпләренең гариза бирүче тарафыннан үтәлүен урынга чыгып бәяләү аудио- яисә видеоэлемтә аша читтән торып аралашу чараларын файдаланып уздырылырга мөмкин.<br>Әгәр гариза бирүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләү барышында фотога һәм (яисә) видеога төшерү алып барылган булса, бу турыда бәяләү актында билге куела һәм аңа җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә вәкаләтле вәкилнең кул куюы таләп ителми. Бу очракта фотога һәм (яисә) видеога төшерү материаллары бәяләү актына теркәп бирелә.<br>Нәтиҗә электрон рәвештә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |

## 1.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлне (процедураны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Министрлык / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмау яисә булуны тикшерү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар проектын әзерләү | Бер эш көне | Россия Федерациясе законнары, шул исәптән әлеге Административ регламент нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмау яисә булу | Гариза бирүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләү актын рәсмиләштерү административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора.<br>Министрлыкның вазыйфаи заты гариза бирүченең лицензия алу таләпләренә туры килүен бәяләү акты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкинлеген билгели һәм Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында боерыгын әзерли, ул Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана.<br>Министрлыкның вазыйфаи заты кабул ителгән карар турында мәгълүматны Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куя.<br>Министрлык кабул иткән карарга бәйле рәвештә югарыда әйтелгән боерык белән бер үк вакытта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында хәбәрнамә рәвешендә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында карар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | рәсмиләштерелә, шулай ук лицензияләр реестрыннан өземтәләр яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә рәвешендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерелә, анда баш тарту өчен нигез булган норматив хокукый актларның тәгаен нигезләмәләренә таянып баш тарту сәбәпләренең нигезләре күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмау яисә булуны тикшерү, дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Нәтиҗә дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты рәвешендә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |
| | Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын карап тикшерү | Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерү көнендә | Карар проектның Россия Федерациясе законнары, шул исәптән әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүе | Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын Россия Федерациясе законнары, шул исәптән әлеге Административ регламент таләпләренә туры килү-килмәве, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты ягыннан карап тикшерә, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты үтәлүен контрольдә тота, дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарга көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен гариза |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | бирүчегә (аның вәкиленә) юллау өчен Министрлыкның вазыйфаи затына юллый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар түбәндәге вакыт эчендә кабул ителә:<br>Министрлыкта Административ регламентның 8.1, 8.2, 8.3, 8.3.1 пунктларында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта) каралган соратуны һәм документларны кабул итү көненнән 15 эш көненнән артык түгел;<br>Министрлыкта Административ регламентның 8.1, 8.2, 8.3, 8.3.1 пунктларында (Административ регламентның 5.1.1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгать иткән очракта) каралган соратуны һәм документларны кабул итү көненнән 10 эш көненнән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарны раслау һәм аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кую административ гамәлнең (процедураның) нәтиҗәсе булып тора.<br>Нәтиҗә дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты рәвешендә Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәп куела |

## 1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау

| Административ гамәлне (процедураны) башкару урыны | Административ гамәлнең (процедураның) атамасы | Административ гамәлне (процедураны) үтәү вакыты | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлне (процедураны) үтәү тәртибенә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы / Россия Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәте автоматлаштырылган мәгълүмат системасы | Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы / электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә (аның вәкиленә) юллау | Дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү көнендә | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең Россия Федерациясе законнары, шул исәптән әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүе | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен раслау һәм дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карарга көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кую административ гамәлне (процедураны) башлау өчен нигез булып тора.<br>Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхси кабинетына, шулай ук соратуда күрсәтелгән электрон почта адресы буенча юллый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне юллана.<br>Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу турында Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
